Татарстан яшьләре

№ 66 (8494)

ПӘНҖЕШӘМБЕ

6 июнь, 1991 ел

Бәясе 10 тиен.

● ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ ● 1920 ЕЛНЫҢ 22 ЯНВАРЕННАН БИРЛЕ ЧЫГА ●



12 ИЮНЬ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТЫН САЙЛАУ КӨНЕ

ҮЗЕБЕЗНЕҢ КЕШЕ

Аның турында тәфсилләп сөйләп торуның әллә ни кирәге дә юк кебек. Чөнки без аның кемлеген шушы вакыт арасында яхшы күрдек шикелле. Татарстаныбызның мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул иткән көннәрдә халык үзе кебек үк сабыр, төпле һәм акыллы улына сокланмыйча карый алмагандыр. Нәкъ менә Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең татар халкына хас сыйфатлары ярдәм итте ул бердәмлекне булдырырга. Бу сүзләрне укыган кайберәүләр: «Тагын мәдхия укый башладылар», — дип, ризасызлыкларын белдерергә мөмкин. Һәркемнең үз фикере. Ләкин соңгы вакытта без кешенең (теләсә кемнең) булган яхшы якларын да күрмәмешкә салышырга өйрәнеп киттек. Демократия, димәк, үч аласы, тиргисе, тәнкыйтьлисе, без дигәнчә булмаганнарны дошман дип атыйсы. Әйе, без бер ярдан икенче ярга бәргәләнергә өйрәнгән. Ә дөньяда урталык дигән нәрсә дә бар. Алтын урталык. Аны дөрес билгеләве, уңга-сулга тайпылмый, ашыкмый-каударланмый баруы ай-һай җиңел түгелдер. Андыйларны уңнан да (сулга каера дип), сулдан да (уңга китте дип) утка тоталар. Безнең Татарстан Республикасы Президентлыгына кандидат булып күрсәтелгән М. Ш. Шәймиев тә нәкъ менә шушы урталыктан баручы. Үзләрен демократ дип йөрүчеләр аны аппарат кешесе, милләтчеләр ягына каеручы оста карьерист буларак бәяләсә, милли азатлык идеясе белән янып йөрүчеләр аңа «халыктан аерылган», «үзәккә сатылган» ише ярлыклар тага. Һәр ике як та үзләрен хаклы дип саный. Чөнки 1959 елны Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап инженер булып эшли башлаган М. Шәймиев 25 яшендә «Сельхозтехника» район берләшмәсе управляющие, 32 яшендә республика министры була. Аннары Республика Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары, КПСС өлкә комитеты секретаре, Министрлар Советы Рәисе, 1989 елдан КПСС өлкә комитетының беренче секретаре. Менә шуларны гафу итеп бетерә алмыйлар «уң» һәм «сул»лар. Бу еллардагы аның эшенә җентекләп бәя биреп тору шулай ук артыклык булыр. Теләгәндә гаепләргә дә, мактарга да буладыр. Ләкин бүген үзебез сайлаган республика Югары Советы тарафыннан 1990 елның апрелендә Татарстан Югары Советы Рәисе итеп сайлап куелган Шәймиев тә бар. Үзендәге һәм депутатлар арасындагы каршылыкларны оста җиңә белгәне, хисләрдән бигрәк акыл белән эш итеп киләчәккә карый алганы өчен аны бүген күбебез яратып өлгерде. Татардагы тыйнаклыгы белән ул республикабызның беренче Президентын сессиядә сайларга дигән фикерне кире какты. Татарстан Республикасы Президентын бөтен республика халкы сайлап куярга тиеш дигән уенда ныклы тора М. Ш. Шәймиев.

М. Ш. Шәймиев Югары Совет Рәисе булып сайлангач ирешкән иң зур казанышыбыз турында әйткән идек инде. Бүген ул республика мөстәкыйльлегенә реаль эчтәлек белән ныгыту юнәлешендә эшли. Дәүләт мөстәкыйльлеге экономик мөстәкыйльлеккә нигезләнергә тиеш дигән принциптан чыгып эш йөртә ул бүген. Бүген Союз һәм Россия буйсынуында булган күпчелек предприятиеләр, беренче чиратта — халык кулланы товарлары җитештерү, нефть һәм нефть химиясе промышленносте куәтләре Татарстан карамагына күчкәндә генә республика бюджетын ныгытырга, халыкның хәлен яхшыртырга мөмкин.

М. Ш. Шәймиевнең җиргә, аның кешеләренә булган мөнәсәбәтен дә ачык күрдек без сессияләр барышында. Ач хәлен тук белми дигәндәй, үз казаннарында гына кайнарга өйрәнгән шәһәр җитәкчеләренең (андый депутатларыбыз аз түгел) авылга бирү турында сүз чыкканда авызларына су капкан яки кирегә сукалаганнарны да акрынлап көйгә китерә белә парламент җитәкчесе. Авылда туганы (Актаныш районының Әнәк авылы) өчен генә түгелдер. Чөнки авылдан чыгып та авылны онытканнар азмыни. Акылы һәм күпьеллык тәҗрибәсе аңа авылдан ерагаерга ирек бирми. Ул бүген колхоз-совхозлар һәм гражданнарның шәхси хуҗалыклары өчен дә бер үк шартлар булдыру ягында. Крестьян җирдә чын мәгънәсендә хуҗа булырга тиеш. Минтимер Шәймиев безнең республикадагы һәр кеше җитештерү чараларына ия булырга тиеш дип саный, милекнең уртак яки берәүнеке дә булмавына каршы чыга. Ул һәр кешегә үз мөмкинлекләреннән тулы файдалану һәм үз хезмәте белән үзенчә яшәү өчен шартлар булдыру ягында.

Бүген килеп туган кризистан чыгу юлын ул эшмәкәрлекне үстерүдә күрә. Ләкин ул базар дип кешеләрнең социаль хәлен оныту ягында түгел.

Минтимер Шәймиевнең иҗтимагый-политик эшчәнлегендә торган кыйбласы — килешү һәм төзү. Шуңа күрә ул экстремистик һәм шовинистик рухтагы бер чиктән икенче чиккә бәргәләнүләрне кабул итә алмый.

М. Ш. Шәймиев республика Президенты Югары Совет белән Татарстан Министрлар кабинеты арасында нәтиҗәле элемтәләр булдыруда, төрле партияләр һәм иҗтимагый хәрәкәтләрнең, социаль катлаулар һәм группаларның ихтыяҗларын үрелдереп баруда зур роль уйнарга тиеш дип саный. Мондый кешенең Президент итеп сайлануы Татарстанның халыкара масштабта абруе үсүенә, республика экономикасын кризистан чыгару проблемаларының тиз арада хәл ителүенә, тәртипне ныгытуга китерми калмас.

Әйе, бүгенге болгавыр тормышта урталыктан бару ифрат дәрәҗәдә кыен эш. Әмма шунсыз алга китеш булуына өмет юк. Бер мәртәбә ышанычыбызны аклаган Минтимер Шәймиев бу юлы да үзен сайлаган халкына тугры булып калыр.



12 ИЮНЬ КӨНЕ якынлаша барган саен күңелләрдәге киеренкелек арта бара. Бу көнне без ирекле Татарстанның тәүге Президентын сайларга тиешбез. Шул ук көнне ТССР Югары Советы карары нигезендә теләгәннәр РСФСР президентын да сайлый алалар. Инде республикабыз шәһәрләрендә Борис Ельцин өчен тавыш бирергә чакырган төсле плакатлар пәйда булды. 3 июньдә Россия демократик партиясенең Татарстан бүлеге Ирек мәйданында митинг үткәрде. Аз санлы халык алдында РСФСР Югары Советы депутаты Вакыйф Фәхретдинов, Казан шәһәр Советы депутаты Рәшит Әхмәтов кебек демократлар Ельцинны күккә чөйделәр. Ирексездән уйлап куясың, кайда Минтимер Шәймиевне яклап чыгарылган плакатлар, ни өчен аны яклап митинглар үткәрелми? Түбән Кама районында хәтта РСФСР президентын сайлауларга килергә чакырган өндәмәләр эленгән. Моның законсыз эш икәнен элүчеләр белде микән?

ТАТАРСТАННЫҢ Демократик көчләр берлеге республика халкын РСФСР президентын сайлауларда катнашмаска чакыра. Анда катнашу тоталитар режим өчен тавыш бирү булачак. Сайлау участокларына килүчеләр РСФСР президентын сайлау бюллетенен бөтенләй алмаска тиешләр. Төрле ялганнарга урын калдырмас өчен сайлау участокларын Демократик көчләр берлеге вәкилләре тикшерүгә алачак. РСФСР президентын сайлаулар бездә рәсми төстә үткәрелми, шуңа да аңа каршы агитация алып бару тыелмый. Бу эштә ярдәм итәргә теләүчеләр 32-23-19 яки 32-73-90 телефоннары буенча хәбәргә керә алалар.

ХАЛЫК депутатларының Вахитов район Советы башкарма комитеты Казандагы барлык иҗтимагый хәрәкәтләргә ТССР Президентын сайлауларга әзерлек чорында башкалада милләтара татулыкны һәм иминлекне саклау максатларында митинглар уздырудан тыелырга сорап мөрәҗәгать итте. 3 июньдә РДПның Татарстан бүлеге митинг уздырды уздыруын, ә менә 4 июньдә Татар иҗтимагый үзәге бу хокуктан мәхрүм ителде...

ӘЛЕГЕ катлаулы заманда җитәкчеләрдән дә күп нәрсә таләп ителә. «Меркурий» физкультура-спорт клубы җитәкче хезмәткәрләр арасында... ату буенча ярышлар үткәрде. 19 команда вәкилләре катнашкан бәйгедә Идел буе районы азык-төлек торгы директоры Ф. Хафизовка тиңнәр булмады.

ӘЛМӘТТӘ юл хәрәкәте яшь инспекторларының III республика слеты булып узды. Берсеннән-берсе катлаулырак сынауларда иң яхшы нәтиҗәне Әлмәт районының Түбән Мактама урта мәктәбе командасы күрсәтте. Аның әгъзалары «Бөркеткәй» Бөтенсоюз лагерена путевка белән бүләкләнделәр. [illegible] Омскида үтәчәк [illegible] тәгәрмәч» Бөтенроссия ярышларында Татарстан данын яклаячаклар. Әйе, әле һаман РСФСР күләмендәге бәйгеләрдә катнашабыз. Кайбер спортчыларыбыз хәтта Бөтенсоюз турнирларында РСФСР командасы өчен чыгыш ясый. Моңа кайчан чик куелыр? Суверенлыкны һәр өлкәдә тормышка ашырырга кирәк бит!

КАЗАННЫҢ Ирек мәйданында ач торучы Фәнил хәзрәт турында хәбәр иткән идем инде. Соңгы вакытта аның шәхесенә тап төшерә торган төрле имеш-мимеш сүзләр таралды, аны аферистлыкта гаепли башладылар. Болар барысы буш сүзләр... Фәнил Әхмәди Уфа мәдрәсәсен тәмамлагач, Азнакай районындагы Актүбә мәчетенең имам-хатыйбы итеп билгеләнә. Узган ел Мәккәдә булып кайта һәм хаҗи исеменә лаек була. Фәнил хәзрәт, дин дәүләттән аерылса да, җәмгыятьтән, сәясәттән аерылмаска тиеш, дигән караштa тора. Шуңа да ул Татарстанның бәйсезлеге өчен көрәшүчеләрнең алгы сафында бара, Ислам-демократик партиясе рәисе вазифаларын башкара.

Айрат САДЫЙК.

СПОРТ·СПОРТ·СПОРТ

КАЗАННЫҢ 3 нче Олимпия резервы мәктәбендә фехтование буенча яшүсмерләр арасында «Олимпия алмашы» дигән Бөтенсоюз ярышлары булып узды. Шпагачылар — беренче, кылыччыларыбыз өченче урыннарны яуладылар, ә менә рапирачыларыбыз бүләксез калды. Шушында ук яшь динамочылар турниры узды. Шпагачы Антон Шейнин шәхси беренчелектә икенче урынга чыкты.

ХИМКИ шәһәренә илнең иң көчле мушкетерлары «Динамо» җәмгыятенең ачык беренчелегенә җыелдылар. Шпагачылар бәйгесендә чемпион булып Казаннан спорт мастеры Юрий Андреев танылды. Шпагачы Игорь Баранов яшь динамочыларның Ригада үткән ил беренчелегендә өченче урынга лаек булды.

МӘСКӘҮНЕҢ «Чертаново» спорт комплексында фехтование буенча яшьләрнең халыкара турниры үтте. Анда, совет спортчыларыннан тыш, Англия, Бельгия, Голландия, Швейцария, Болгария, Польша вәкилләре дә чыгыш ясады. Әлеге ярышларда татар егете — тренер Фәрит Хәсәнов шәкерте, Казан дәүләт педагогия институты студенты Айрат Әбделманов та катнашты һәм кылыччылар арасында икенче урын белән канәгатьләнде.

Лев СОСНИН.
(Штаттан тыш хәбәрчебез).



Чиләбе студентлары арасында яңа мода таралды — алар аяк киемнәрен ялан тәпигә генә кия башладылар. Әлеге моданы сатуда оекбашлар булмау китереп чыгарды. Хәер, Парижда да шулай киенергә яраталар, дип сөйлиләр.

• • •


Мәскәү университетының журналистика факультетында курс эше яздырып алу өчен быел... 15 доллар түләргә кирәк. Безнең акчага күчерсәк, бу 300—400 тәңкә дигән сүз. Шунысы кызык: доллар белән түләгәндә, яхшы билге алу мөмкинлеге зуррак.

• • •

Советлар Союзының элеккеге тышкы эшләр министры Эдуард Шеварднадзе Перес де Куэльярны БМОның генераль секретаре постында алыштырудан баш тартты һәм аңа ышаныч белдерде.

Кая китә бу татар?!

Фәнзамен БАТТАЛ



Кызык яки мавыктыргыч нәрсәләр генә укырга яратучы кешеләрне алдан ук кисәтеп куям: бу язмам сезнең күңелгә хуш килмәячәк. Рухны күтәрә торган җөмләләр бөтенләй булмас монда, мөгаен. Шуның өстенә яртылаш арифметикадан, ягъни исәп-хисаптан торачак бу мәкалә.

...1983 елның җәе. Гаҗәеп матур иртә. Карашым белән дистәләрчә чакрымнарга сузылган киңлекләрне буйлап, биек яр башында «айгыр» янында хозурланып утырам. (Өфе кешеләре Салават Юлаев һәйкәлен гади генә итеп «айгыр» дип йөртәләр.) Аяк астында Агыйдел җәйрәп ятә, арырак болыннар, өрәмәлекләр, ниндидер авыллар...

Башта-зиһендә бернинди гамь дә, мәшәкать тә юк; тәнне — кояш, күңелне күз алдындагы манзара иркәли. Кичләрен йөзләрчә татар һәм башкорт яшьләре җыелып уеннар оештыра торган бу киң мәйданда берүзем утыруны да әйтсәм, ял итү өчен шушыннан да кулайрак урын хакында хыялыңа да китерерлек түгел.

Шулчак артта сәлам биргән тавыш ишетелде. Борылып карасам, илле яшьләр тирәсендәге бер ир. Атлетик фигура диләрме әле, гәүдәсе шул чама: мәһабәт, җиңел хәрәкәтле, өстендә спорт костюмы. Карашыннан, йөзеннән дә күренеп тора: аек акыллы, омтылышлы кеше булырга тиеш бу!

— Бергә утыруга каршы түгелме сез? — дип сүз башлады атлет. Хәл-әхвәл белешә, таныша башлагач, аңлашылды; подполковник дәрәҗәсендәге офицер икән. Хезмәтен күптән түгел тәмамлаган, пенсиягә чыккан. Яшәү өчен үзенә шәһәр сайлый. Кайсы гына шәһәрдә яшәргә теләсә дә, берничә ай дәвамында фатир бирергә тиешләр икән.

— Башта Казан белән таныштым. Архитектура яклары да баерак булгач, шунда яшәү нияте бар иде. Инде менә Уфаны сайладым. Шәһәр властьлары фатир юнәткәнче кунакханәдә яшәп ятмышым...

— Ник, Казан ошамадымы?

— Казан үзе матур ул болай... Ләкин аның халкы, бигрәк тә татарлары ошамый миңа.

Үземнең нәкъ менә татар, Казан татары икәнлегемне сиздермәскә тырышып, битараф кешедәй сорап куйдым:

— Шулай да кай яклары белән ошамый алар?

Әңгәмәдәшем кинәт кызып-кабынып китте:

— Союз буенча күпме йөрмәдем, кайларда гына хезмәт итмәдем, ә татар кебек халыкны күрмәдем. Каян килә аларга бу кадәр юашлык, мескенлек, күндәмлек?! Ул халык миңа хуҗа кулындагы муенчакка бәйләнгән кәҗәне хәтерләтә: суйсаң да карышмый, кыйнасаң да риза, ашатмыйча саусаң да сөт бирергә тырыша... Менә, күрәсез бит, Уфа кибетләре төрле ризык белән тулы. Кер дә җаның теләгән кадәр сатып ал. Ә тегендә талон икән. Ягъни ни грамму больше. Нинди генә юллар белән кырмады бу халыкны Россия, иллә дә мәгәр ләммим... Самоубийца халык ул татар. Шуңа күрә ярты мең ел буена сан ягыннан да артмады.

— Дүрт-биш йөз ел элек татарның күпме булуын төгәл генә әйтеп булмый бит. Бәлки, арткандыр да,— дип куйдым, татар халкында йомышым юк кеше сыман.

— Аның уналтынчы гасырдагы санын чамалап була, — дип, бер-бер артлы бармакларын бөгә башлады офицер. — Ул чакта урысларның сигез-ун миллион булуы тарихтан мәгълүм. Монысы булды бер факт. Казан ханлыгын җимерү өчен ничәмә-ничә походлар оештырып карамаганнар урыслар! Әмма татарлар аларны һәрвакыт пыр туздырганнар. Димәк, сан ягыннан урыслар белән тигез булганнар дип әйтә алабыз — монысы булды икенче факт... Ну, ярый, ике мәртәбә кимрәк булган дип уйлыйк. Бу очракта да татарларның халык саны 60—70 миллион булырга тиеш бит хәзер. Әнә бит урыслар шул ук биш гасырда унбиш-егерме мәртәбә арткан!

Татар икәнемне белеп алгач, яңа танышым урынында утырып тора алмас булды. Хәтта төйнәлгән йодрыгы борынга тия язды.

— Менә шулай бетерәләр инде халыкны, кадерлем. Аның җитештергән азык-төлеген читкә ташып, үзен талонга утырту да — халыкны бетерергә тырышуның бер юлы. Уйлап кына кара син: ризыгында аксым булмаган халык үрчиме? Яисә әйт син миңа: алдагы елларда да ашау ягы такыр булачагын белгән гаиләдә бала табарга ашыгаларммы? Шул-шул менә!

Ниһаять, әллә арыды, әллә «күпме сөйләсәң дә барыбер файдасы юк» дигән нәтиҗәгә килде подполковник, кулын селтәп, хәлсезләнеп калды.

— Ярый, үзегез карагыз... Бетәсегез килсә — бетегез, үсәсегез килсә — үсегез... Нефтегезне дә бушлай бирегез, ризыкларыгызның күрше өлкәләргә таратылуына да риза булып яшәгез...

* * *

Аңа кадәр дә татар халкының үткәне, хәзергесе нык уйландыра иде мине. Ә менә «айгыр» янындагы шушы сөйләшүдән соң милләтнең язмышы бөтен чынбарлыгы белән күңелгә сызлавык булып кучте сыман. Әледән-әле сулкылдап, йөрәкне талап тора.

Өлкәнрәк кешеләр хәтерли әле: без, сугыштан соң үскән балалар, ата-аналарыбыз алдында тәүфыйклы, намуслы булырга тырышсак та, бер гонаһтан тыела алмый идек: кайда гына яшермәсеннәр, конфет-шикәрнең эзенә төшеп, җае килгән саен кымтырыклап тора идек. Мескен әнкәйләр, әллә белеп, әллә белмәгәнгә салышып: «Алуын да алып торам, тотуын да сак тотам инде югыйсә. Кая китә бу конфит?!» дип аптырыйлар иде.

Менә мин дә күп еллар буе үз-үземә бер сорау бирәм:

— Кая китә бу татар?!

Чыннан да аптыраш бит: гасырлар буе башка халыклар кебек үк туа торган, яшәргә, нәсел-ыруны сакларга тырышкан. Әле ничек кенә үрчегән бит! Әйтик, урыслар кебек эчүгә бирелмәгәнлектән, тәмәке тартуны — зур гонаһка, аборт ясауны кеше үтерүгә тиңләгәнлектән, җидешәр-уникешәр бала тудырып үстерү гомер бакый табигый хәл саналган. Шулай булгач (чыннан да гаҗәп бит!), кая китә бу татар? Кайсы чорның кыравы нык суккан аның тамырына? Киләчәктә безне нинди язмыш көтә? Әлеге сызлавык яңадан-яңа сораулар тудыра...

1552 елның 2 октябрендә Казан ханлыгы урыс кулына кергәч, татар халкының язмыш тәгәрмәче бертуктаусыз кирегә әйләнә. Тарихны күпме генә өйрәнмә, никадәр генә күп белмә, татар халкының үсешенә уңай йогынты ясаган бер генә ел да таба алмассың.

Уналтынчы гасыр урталарында урыс халкы, чыннан да, сан ягыннан 8—10 миллион кеше саналган. Бөтен көчен, бөтен сәләтен басып алуларга туплаган бу халык 1548—1550 нче елларда гына да Казан ханлыгына ике мәртәбә «бөек һөҗүм» ясый, ләкин уңышка ирешә алмый. Урыс елъязмачыларының истәлекләреннән күренгәнчә, «Иван IV вернулся из этих походов со многими слезами», ягъни урыс илбасарлары җимерелеп-таркалып кайта. Төрле тарихчылар төрлечә фараз кылып караса да, татар халкының ул вакыттагы саны-исәбе хакында мин, шуларның берсенә дә бирелмәстән һәм игътибар да итмәстән, үз-үземә чираттагы сорауны кабат бирәм: «Шушы кадәр урысның арт сабагын укыту өчен татар халкының күпме булуы шарт?» (Тарихчылар үпкәләмәсен, мин ул чорга бары тик мантыйк, ягъни логика күзлеге аша гына карарга мәҗбүр.) Һәрхәлдә, урыс халкының кимендә яртысы кадәр булганлыгын бәхәссез дип танырга кирәк. Бәс шулай икән, ник без хәзер 77 түгел, бәлки нибары 7 миллион?

Тарихтан мәгълүм булганча, татар җирен алуның беренче атнасында ук Казан шәһәрендә һәм аның тирәюнендә бер генә татарны да калдырмыйча үтереп бетерәләр. Безнең милләтне җир йөзеннән юк итү яки аз санлы халык итеп калдыруның иң тәүге чарасын урыс «бөек»ләре аеруча зур тырышлык белән башкара. Үтерелгән татар мәетләре бөтен урамнар буена эскерт булып сузыла, Казан елгасы, юлына мәетләр тыгылганлыктан, ярларыннан чыга, ә суы, аз да түгел, күп тә түгел, кан төсендә...

Югыйсә басып алучы ил күзлегеннән караганда, булды дигән сүз бит инде бу. Башка токым илбасарлары, каршы якның армиясен таркаткач-кыргач, гадәттә, яуланган илне тынычландырырга, халкын файдалы хезмәткә җигәргә тырыша. Ә бу очракта бер гонаһсыз халыкны кырып бетерү, һич югы, чукындырып, илбасарлар диненә аудару сәясәте эзлекле дәвам ителә.

Менә безнең кайбер төртмә телле бәндәләребез керәшеннәрдән көлмәкче. Имеш, урыска сатылганнар... Билгеле, урыс динчеләре чиркәүгә кереп чыккан татарларга да акча сузарга әзер торганнар. Хөкемдарлар җир дә биргәннәр чукынган кешеләргә. Ләкин тарихны өйрәнгән саен ул чордагы вәхшилекләрнең тиңе юклыгына инанасың.

1552 елның ноябрендә урыс гаскәрләре Казан ханлыгының бөтен төбәкләренә тарала. Иң яраткан шөгыльләре — аналарны балалары белән бергә боз ката башлаган елгаларга, күлләргә тутыру. Юк, исән калырмын димә, чөнки «...разъезжали по реке на лодке и топорами и рогатинами топили тех, кому удавалось всплыть» яки: «связанных женщин и детей бросали в воду и заталкивали под лед палками». Безнең чорда инде бу кадәр генә урыс текстларын һәркем аңлый, шуңа күрә тәрҗемә итеп торуны кирәк тапмыйм.

Чукындыруның иң отышлы алымнары, мөгаен, ут ярдәмендә башкарылгандыр. Чукындыру урыннарында, гадәттә, биниһая зур казан кайнап утыра, кем әйтмешли, болындай таба кызып тора. Син сайларга тиеш: чукынсаң — исән каласың, юк икән — сине кайнап торган суга ташлыйлар яки табада кыздыралар. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, урыс җәлладлары опричнина чорында мондый җәзаларны үз кешеләренә карата да кулланганлыйлар. Мәсәлән, явыз Иван үзенең шәхси табибы Елисей Бомилейны «велел зажарить на огромном вертеле», ягъни шашлык кыздырган кебек... «Гаепләнә» дарылы мичкә өстенә утыртып янә дә ут төртеп шартлату да киң таралган бу чорда. Явыз Иванның җәза мәсьәләсендә нинди тапкыр һәм сәләтле булуына исең китәрлек! СССР Фәннәр Академиясе тарафыннан нәшер ителгән «Иван Грозный» дигән китаптан да (1983 ел, авторы Р. Скрынников) күренә бу: «После разгрома Казани Грозный велел казнить увезенных в Новгород мусульман, отказавшихся принять христианство, в завоеванном Полоцке приказал утопить всех евреев, собственноручно душил своих детей, неугодных богу».

Димәк, әле безнең халыкны үз якларына алып китеп тә җәзалаганнар. Күрәмсең, монысы кызык өчен, тамаша өчен...

Казан ханлыгы җимерелеп дүрт ел узгач, исән калган татарлар тагын бер мәртәбә калкынып, баш күтәреп карыйлар. Урыс тарихына «казанское возмущение» билгеләмәсе белән кергән бу вакыйгадан соң татарларны тагын бер мәртәбә канда коендыралар.

Казан ханлыгын татарлардан арындыру (үзләренчә, «очищение») чорында урысларның үзәк төбәкләрендә ачлык һәм, аның юлдашы буларак, чума башлана. Ачлыкның сәбәбе бер генә: бөтен ир-ат сугышта йөрү сәбәпле, җирнең хуҗасы калмый, күп еллар тәрбия күрмәгән миллионнарча гектарлар гамәлдән чыга. Погромнар да киң колач ала. «Голодающие в глухие зимние ночи крали тела убитых людей и питались ими, иногда солили человеческое мясо в бочках». Ә чумага дучар булганнарны тере килеш яндыралар.

Бер караганда, афәт бу. Ләкин Иван моның авырлыгын да татарлар җилкәсенә сала, төгәлрәге, татарларны тәмам бетерү максатында файдалана; үзенең күңеленә хуш килеп бетмәгән боярларны... «сослал в вотчину свою в Казань на житье з женами и з детми». Тарихның буеннан-буена тәрбия күргән, уңдырышлылыгы белән дан алган җирләрне үзләштерү, татарларны тагын да кыру яки коллыкка төшерү өчен булачак алпавытларын җибәрә. Күп булганмы алар, азмы? Урыс елъязмачылары үзләре әйтсен: «Казанской землицы не хватило для сколько-нибудь сносного обеспечения поселенцев».

Укучыда мондый фикернең тууы ихтимал: «Кансыз булуын булганнар да, ләкин бит урыслар татарларны кырып бетермәгән...» Чыннан да, татарның бер өлеше ничек исән кала алган? Әмма дөрес аңлашылсын, Җәллад Иван чирүенең мәрхәмәтле булуыннан түгел бу. Бары тик чит илләр туктарга мәҗбүр итә татарларны тәмам юк итүдән. Чөнки ул чакта да илләр белән илләр аралаша, хәзерге кебек үк тоталитар дәүләтләрдән җирәнү бар, араны өзү бар, сәүдәне туктату бар... Урыс дәүләтендә, эчке һәм тышкы вәхшилегенә протест белдереп, Рим папасы, мәсәлән, бөтен илләрне «Мәскәү тираны белән дипломатик мөнәсәбәтләрне өзәргә өнди».

Ничек кенә булмасын, урыс кулы астына кергән елларда ук татарларның бик аз өлеше исән кала. Чөнки күпләргә мәгълүм: бер-бер артлы Әстерхан ханлыгы, Нугай урдасы һәм Себер ханлыгы да басып алына. Билгеле, тарих расларганга ышансак, башкортлар урыс вассаллыгын үз теләкләре белән кабул итәләр. Ләкин ул чорда да хәзерге Башкортстан җирендә татарларның күп яшәвен истән чыгармасак, иң каты җәзаларның, гомер кисүләрнең беренче чиратта кемнәргә юнәлдерелүе аңлашылса кирәк...

Фәһемле һәм үз милләтенең тамыры белән кызыксынучы татар кешеләре өчен бу чорның фаҗигалары да, тарихы да азмы-күпме мәгълүм.

— Кая китә бу татар?! — дип аптыраганда, без иң әүвәл шушы чорга дөрес бәя бирергә тиеш. Арифметиканы искә алган идек бит. Аны да эшкә җигә белергә кирәк, милләтнең үткәне, бүгенге исәбе-саны турында фикер йөрткәндә. Мәсәлән, 1552 елда суга батырылган бер егет һәм бер кыз хакында гына уйланыйк. Ничәү алар? Әлбәттә, ул вакытта нибары икәү! Ә менә бүген, минем исәпләвемчә, аларның нәселе берничә йөзгә, хәтта меңгә җиткән булыр иде. Күреп торабыз бит, кайбер нәсел өченче буында ук утыз-кырык кешегә җитә.

1952 елдан соң исә, һәр буынның яшен 20 ел дип санасак (кияүгә бирерлек яки өйләндерерлек яшьне алабыз), 20—22 буын дәвамында күпмегә җитәр иде теге яки бу нәсел?

* * *

Рәсәй кочагында күпме генә халыклар, ыруглар эреп юкка чыкмады да, күпме генә телләр онытылып бетмәде! Алар инде тарих чоңгылыннан бер чакта да калыкмаячак...

Теге яки бу халыкны юкка чыгаруның бихисап чараларын, юлларын тапты бу империя, үтерү-кыру, икътисади яктан бөлгенлеккә төшерү, булган азык-төлекне талап, ачлыкка дучар итү, динне һәм телне мәсхәрәләү, гореф-гадәтләрдән мәхрүм итү, басып алынган халыкларны үзара сугыштыру... Хәер, гасырлар буе эзлекле рәвештә алып барылган бу чараларны бер сулышта гына санап та бетермәле түгел һәм бу очракта үз алдыма андый максатны да куймыйм. Ник дигәндә, һәр халыкның урынына-җиренә, күплегенә-азлыгына, күрше милләтләр белән нинди мөнәсәбәттә булуына, хәтта табигать шартларының үзенчәлегенә карап башкарылган вәхшилекләр, пычрак гамәлләр алар.

Ил-мәмләкәт, дәүләт, хөкүмәт, идарә гыйлемнәре, халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләү мәсьәләләре хакында борынгы заманнарда ук тирән уйланганнар, уртак кануннар табарга тырышканнар.

[Ахыры бар].



Көнбатыш Германия психологы Руппе әфәнде газетада гадәти булмаган игълан бастырып чыгарган:

«Клиентның үзенә үлчәп гыйффәт билбавы әзерлим».

Гаҗәпләнүенә каршы, бер көн эчендә ул 17 заказ ала. Дөрес, ул билбау-фәлән әзерләмәгән, әмма бу проблема белән чынлап торып кызыксына башлаган. Баксаң, ортопедик аяк киемнәре һәм бандаж тегүчеләр әле бүген дә заказ буенча гыйффәт билбавы тегәләр икән ич!

Урта гасырларда гаиләләрне җимерелүдән саклап калу өчен бу ысулдан файдалану шактый киң таралган булган. Чөнки бу чара иренә хыянәт иткән хатынны учакта яндыру, таш белән кыйнап үтерү, башын кисү кебек җәзалар янында гуманлыгы, арзанлыгы һәм гадилеге белән аерылып торган. Әйе, хыянәт өчен җәза бары тик хатыннар өчен генә каралган!

Интим мөнәсәбәтләргә карата ни өчен соң ике төрле мораль яшәп килә? Гомумән, секста нәрсәне әхлаклы, нәрсәне әхлаксыз дип санарга? Аттила Бадьнони үзенең «Мәхәббәт: уянудан гармониягә кадәр» дигән китабында әнә шулар хакында уйлана. Укучыларыбыз игътибарына «Прогресс» нәшрияты бастырырга әзерләгән бу китаптан бер өзек тәкъдим итәбез.

Гыйффәт билбавы кемгә кирәк?

Җәмгыятьтә элек-электән үк сексны оят нәрсә дип исәпләү яшәп килә. Мондый караш болай да кыенсынучан кешеләрнең оялуын тагын да арттыра. Урынсыз оялчанлык төрле формаларда чагыла. Берәүләр, мәсәлән, сексны ачыктан-ачык сүгәләр, ирекле мәхәббәтне фәхешлек дип кабул итәләр, урамда үбешүче, пляжда ялангач йөрүчеләрне нәфрәт белән күзәтәләр.

Икенчеләр берәүгә дә бармак төртеп күрсәтмиләр, әмма форсат чыкканда секстан ерак булуларын исбатларга тырышалар. Күпләр никахка кадәрге җенси мөнәсәбәтләрне гомумән әхлаксызлык дип саный. Урынсыз оялчанлык рамкаларында тәрбияләнгән егетләргә интим мөнәсәбәтләр гөнаһ эш дигән фикер сеңдерелгән.

Яшьләр сукыр түгел. Алар үзләренә мораль укыган теге яки бу кешенең нинди тормыш белән яшәвен — бер төрле сөйләп, икенче төрле эшләвен тиз чамалыйлар. Шушы оялчанлык берәүләрне өлкәннәргә карата тупасландыра, алар белән ирексездән бәхәсләшүгә этәрә. Алар әйткәннең киресен эшләргә омтылу бериш яшьләрне җилбәзәклеккә, хәтта йөгәнсезлеккә китерә.

Урынсыз оялчанлык мәхәббәтне үтерә. Кыскасы, кеше кайда ялган, кайда дөреслек икәнен ачык кына аңлый да алмый. Җенси мөнәсәбәтләргә карата ике төрле мораль урынсыз оялчанлык баласе. Ул җенси яктан үз-үзен тотышында ирләргә бер, хатыннарга икенче таләп куя. Менә шуннан ирләрнең өстенлеге формалаша. Күпчелек ирләр хатыннарының җенси активлыкка омтылуын бер дә өнәмиләр. Кайбер ирләр өчен хатынының җаваплы эштә булуы гаилә өчен бөтенләй куркыныч. Андыйлар, хатын җәмгыятьтә абруй казанса, бу хәл иренең абруена нык суга дигән фикердә торалар. Шунысы кызык, әхлаклы, гыйффәтле булуны күп очракта бу яктан үзләре гөнаһлы ирләр яклап чыга.

Безнең эрага кадәр өченче меңъеллыкта ук инде хыянәтче хатыннарны җәзалау законнары яшәгән. Яңа Вавилониядәге никах килешүләрендә иренә хыянәт иткән хатынны үлем җәзасына тарту каралган булган. Борынгы славяннарда да нәкъ шундый ук хөкем яшәгән. Ә ирнең хыянәте гаепкә саналмаган. «Ир кеше хокукларны табигатьтән һәм аңардан өстен көчләрдән алган...» дип исәпләгәннәр.

Ике төрле мораль төшенчәсенең тамырлары әнә кайларга китә.

Ә бүген тугрылык төшенчәсе ничегрәк тора соң? 1978—1979 елларда Венгриянең берничә шәһәрендә һәм авылларында үткәрелгән сорашулар күрсәткәнчә, ике еллык гаилә стажы булган ирләр арасында хыянәт итүчеләр 12 процент, биш еллык стажлылар арасында 20 процент, ун ел яшәүчеләр арасында — 26, унбиш ел яшәүчеләрнең 39 проценты хыянәт иткән. Гаилә стажы тагын да күбрәк булган ирләр арасында маҗаралар эзләүгә омтылу кимегән.

Хатыннар арасында бу күрсәткечләр түбәнрәк. Ике еллык гаилә стажы булган хатыннарның — 7, биш еллык стажлыларның — 13, ун еллык стажлыларның — 16,5, унбиш еллыкларның 22 проценты иренә хыянәт иткәнлеге мәгълүм булган. Утыз ел ир белән яшәүчеләр арасында бу сан 8,5 процент тәшкил итә. Дөрес, монда бер үзенчәлекне искә алырга туры килә, хатыннар үз маҗаралары турында бик теләп сөйләмиләр.

Әле мәхәббәттә тугрылык төшенчәсен кем ничек аңлый бит. Гадәттә чит кеше белән җенси мөнәсәбәткә керүне хыянәт дип санарга күнегелгән. Әмма башка кеше белән үбешүне дә хыянәт дип исәпләүчеләр бар.

Яшьләр арасында исә никахны үзенчә бер килешү дип кенә караучылар күбәйде. Бу очракта финанс эшләре һәм тышкы кайбер элементлар гына ир белән хатын өчен уртак була.

Нью-Йорк социологы Мейер Хакерның фикеренчә, ир кешенең сексуаль уңышы— аның эшлеклелек уңышын билгеләүче сыйфат. Үзен күрсәтергә теләгән ир иң әүвәл хатын-кыз күңелен яуларга сәләте булуын исбатларга тиеш.

Сүз уңаенда шуны да әйтик, әхлак төшенчәсен һәркем үзенчә аңлата. Ирләрнең күпчелеге буйдак ир ирле хатын белән теләсә кайчан җенси мөнәсәбәткә керә ала дип исәпли. Алар әле ирле хатынны да карата алулары белән мактанырга яраталар. Һәм моны «батырлык» дип саныйлар.

Бериш ирләр өчен тугрылык дигән төшенчә бөтенләй юк. Андыйлар форсат чыкканда теләсә кем белән җенси мөнәсәбәткә керәләр. Яшь кызларның шактые мәхәббәткә хокукны үзләренә ошаган теләсә нинди ирне (хатыны, балалары булуга карамастан) гашыйк итү мөмкинлеге дип уйлый. Социологлар урта мәктәптә укучы 700 кызга мондый сорау белән мөрәҗәгать иткәннәр: кыз кешенең хатынлы ирне яки сөйгән кызы булган егетне үзенеке итәргә мораль хокукы бармы? Бу сорауга кызларның 68,6 проценты уңай җавап биргән. Күргәнебезчә, бүген әхлак нормалары элеккегедән нык аерыла.

Хыянәткә китергән сәбәпләр арасында кызыксынучанлык; маҗараларга сусау шактый зур урын тота. Бу хисләр ирләргә дә, хатыннарга да хас. «Күреп торыгыз, бу кырыс начальник миңа үлеп гашыйк булачак... Аның белән ялга барудан мин нәрсә югалтам? Ә бу танылган француз хатыннары чынлыкта ничегрәк икән? Ә итальян ирләре?» Иң-иң тугры кешедә дә әнә шундый кызыксыну туарга мөмкин ич. Ә инде күңелендә шикле уйлар булган кешедә туа да туа: «Мин шундый салкын микәнни соң? Әллә иремә генә шулай тоеламы? Мин нишләп импотент булыйм ди, сынап карыйм әле?»

Ирекккә, бәйсезлеккә омтылу да еш кына очракларда хыянәткә сәбәп була. Бигрәк тә бәйдә торгандай күзәтчелек астында торучылар җае туры килгәндә ычкынырга тырыша.

Ни генә булмасын, башкаларны гаепләргә, аларга хөкемдар булырга ашыкмыйк, бер-беребезнең шәхси тормышын ихтирам итәргә өйрәнсәк яхшырак булыр. Дөньялар кайсы якка гына үзгәрмәсен, хисләр һәм тойгылар өермәсендә егылмаска тырышып, үзебез сайлаган ярны бәхетле итү турында кайгыртыйк. Ирләргә дә, хатыннарга да азгынлык сазлыгына төшү озак түгел. Ә менә аңардан бер-береңне саклап калу кыенрак.



«Сердәш»нең соңгы чыгарылышында («Татарстан яшьләре», 51—52 нче саннар) басылган хатларга җавап йөзеннән өч атна эчендә генә дә 300 дән артык хат килде. Алар әле дә килә тора. Иң күп хатлар ике Алсуга, Гөлчәчәккә, Таңчулпанга адреслана. Менә аларның кайберләре.

Алсуга

Ул: «Күршебездә яшәүче бер абыйны яратам, аңа 29 яшь, ә миңа 15 яшь», — дип язган иде, яшьтәшләреннән киңәш сорады. Аңа менә нәрсәләр язалар.

• • •

Алсу! Син егетнең яшенә карама! Бу бит мәхәббәт! Ничек шәп булган. Арагызда 14 яшь аерма булса соң. Егетләр картаймый ул, кызлар картая. Ул риза икән, дуслаш, үкенмәссең.

Яшьтәшең ГӨЛНАРА.
Әлмәт.

• • •

Алсу, сеңелем, ашыкма! Менә мин дә синең кебек юләрләнеп үземнән 14 яшькә олы егеткә кияүгә чыккан идем. Ләкин кызыбызга ун яшь тулгач аерылыштык. Югыйсә начар тормадык. Мин аны картка санадым. Хәзер бик үкенәм. Яшьлек юләрлеге белән өч кешене бәхетсез иттем. Ул да өйләнми, мин дә ялгыз, бала атасыз үсә. Инде кызыма 14 яшь. Ул хәзер «Сердәш»не укып бара. Бөтенесен үзе аңлый.

ӘНИСӘ апаң.
Чистай.

• • •

Алсу! Сабыр ит! Дөрес, мәхәббәт яхшы нәрсә, мин аңа каршы булырга киңәш итмим, әмма бүгенгене генә түгел, алдагысын уйла! Ирең картаеп үләр, ә син яшь-яшь калып балалар үстерерсең... Менә ничек бит ул тормыш.

Хәлим ӘМИНОВ.
Октябрь районы,
Яңа Иглай авылы.

• • •

Алсу! Син ул егет белән йөрсәң хур булачаксың, белеп тор. Сиңа үз яшьтәшләрең дә бетмәгән. Әле бик иртә. Әллә кемнәрне очратырсың әле.

Сәлам белән, СИРИНӘ,
7нче сыйныф укучысы.
Яңа Чишмә районы,
Тат. Волчья авылы.

• • •

Алсу! Берүк ышанма карт егетләргә! 15 яшь—кызларның иң башсыз чагы, дип олылар белми әйтми. Миңа да 15 кенә яшь булса да, мин үзем күпне күрдем. Шуңа күрә сине ялгышудан кисәтәсем килә.

МИЛӘҮШӘ.
Азнакай районы.

Без сине көтәбез, Гөлчәчәк!

(«ЧЫГЫП КЫНА КИТӘР ИДЕМ», «Т. Я.», 51—52 НЧЕ САННАР)

«Иремнән аерылдым, ике балам белән әти-әнием янында торам, ләкин үземне фатирда торгандай хис итәм, әти-әни гел мине куалар», — дип язган иде Гөлчәчәк. Аңа адреслар атап, чакырып язучылар бик күп. Шуларның кайберләре.

• • •

Гөлчәчәкнең язмасын укыгач йөрәкләрем әрнеде. Ничек инде үз балаңны өйдән куарга? Бу бит башка сыймый. Җитмәсә, ике бала белән!

Миңа 32 яшь. Әнием белән генә торам, балаларны бик яратам. Ялгызлыктан арыдым. Гөлчәчәккә хат язар идем. Сезгә рәхмәт белдереп,

Рафаэль НӘБИУЛЛИН.
Минем адрес: 422220, Әгерҗе районы, Татар Шаршадасы авылы.

• • •

Гөлчәчәк! Кил минем яныма, бергә-бергә тормыш корырбыз. Мин өйләнмәгән саф егет. 31 яшьтә. Авылда әти-әни белән яшим. Риза булсаң, хатымны җавапсыз калдырма.

Ранет ГЫЙЛЬФАНОВ.
Башкортстан,
Краснокама районы,
Кузгау авылы.

• • •

Гөлчәчәк! Миңа да 21 яшь. Әнием белән авылда яшибез. Шәһәргә чыгып киткән идем, авылымны сагынып кире кайттым. Кил безгә, Гөлчәчәк. Күңелебез киң безнең. Әни дә, мин дә балаларны яратабыз. Күрше-тирә бала-чагасы гел бездә. Үкенмәссең, көтәбез, Гөлчәчәк!

Рузалия ВӘЛИЕВА.
Азнакай районы,
Югарлы Стәрле авылы.

• • •

Үз баласын куган ата-ана нинди була микән ул? Шул хатны укыгач, йөрәгем өзелде. Гөлчәчәк! Кайт син, балам, безнең авылга. Сарман районы, Чукмарлы авылында ялгыз карчык Гыйльмеямал әби—сине көтә.

• • •

Гөлчәчәк! Риза булсаң, кил безгә! Фатир табарбыз, балаларыңны бакчага урнаштырабыз. Без яшәгән шәһәрдә татарлар бик күп. Бер бик әйбәт татар егете дә бар. Фәрит исемле. Фатиры да бар, балалар ярата. Гөлчәчәк! Хатыңны һәм үзеңне көтәбез.

БАСЫЙРОВЛАР гаиләсе.
Адресыбыз: 472812, Казахстан ССР, Саткаев шәһәре, Ультаус урамы, 100, 33 нче фатир.

• • •

Гөлчәчәк, безгә кил! Мин карт әнием белән генә торам, 25 яшьтә, колхозда тракторчы булып эшлим. Риза булсаң, хат яз. Аңлашырбыз.

Адресым: 422207, Әгерҗе районы, Тәбәрле авылы, Заһид Гариф улы Закиров.

«Кем генә аңлар?»

«Өзелеп сөйгән егетем бар иде, ташлады, тыйнаклыгымны ошатмады...». 17 яшьлек Таңчулпан шулай дип язган иде.

• • •

Таңчулпан! Синең хатны укыгач, дөньяда яхшы күңелле кызларның барлыгына тагын бер кат шатландым. Мин нәкъ синдәйләрне көтәм.

ИЛЬНАМ, 21 яшь.
Арча районы.

• • •

Синең кебекләрне эзләп әле дә кызлар белән танышa алганым юк. Син нәкъ минем хыялдагы кыз.

ВИНАРИС, 20 яшь.
Башкортстан,
Дүртөйле шәһәре.

• • •

Безнең авыл егетләре эчкән-тарткан кызларга җирәнеп карый. Мәҗлесләрдә барысы да кызларның үз-үзен тотышын күзәтә. Җан биздергечләреннән тизрәк кача. Син дөрес юлда, Таңчулпан!

Актаныш егете, 22 яшь.

• • •

Син бәхеткә иң лаек кеше, Таңчулпан!

Уңышлар теләп,
Э. С. 18 яшь.

Нәрсә булды сезгә?

30 апрельдә чыккан «Татарстан яшьләре»ндә минем иң яраткан материалларым — хатлар сәхифәсе һәм «Сердәш» басылган. Ләкин йөрәгем жу итеп китте. Инде «Сердәш»тә дә шәрә хатын бастыра башладыгыз. Ялгышмасам, берике ел элек «Сердәш»тә аның төп билгесе сыман каенга сөялгән матур сагышлы кыз рәсеме чыга иде. Мин аны дәфтәремә дә күчереп ясаган идем. Ә бу сәхифәдәге рәсем шул элеккегесен заманча мәсхәрәләү булып тоелды.

Күпме газета алам, берсендә дә сезнең газетадагы кебек шәрәләр басылмый. Сез чаманы югалтасыз. Әлбәттә, минем фикер сезне кызыксындырмас. Сезгә бит популярлык кирәк. Ләкин шундый рәсемнәрегез белән без яратып укыган газетаны укымас итәсез инде.

Айсылу САФИНА,
27 яшь.
Волгоград өлкәсе.



Мәхәббәтне эзләр алып килде. Н. ТУГАНОВ фотосы.





Безнең бәйрәм

Бәйрәмнәребез бихисап, ләкин шулар арасында иң якын булганы, күңелебезгә хуш килгәне — Сабантуй. Сабантуй — ел буена көтеп алынган, балалар өчен дә, олылар өчен дә шатлыклы булган милли бәйрәмебез.

Быелгы Сабантуйларны беренче булып Питрәч районы хезмәткәрләре башлап җибәрде. Һәм алар моңа лаек та: кыр эшләрен үз вакытында, сыйфатлы итеп төгәлләделәр.

Тормыш-көнкүрешебез бик әйбәт булмаса да, Сабантуй бәйрәме башка көннәрдән аерылып тора. Чөнки әби-бабалардан, әти-әниләрдән күреп килгән гадәт буенча җыен, Сабантуй өстәленә кагылгысыз дип еранкарак яшерелгән тәм-том, күчтәнәч куела, бәлешләр, төрле таба ашлары пешерелә. Киемнәрнең дә без бу көнне иң матурларын киябез.


Быел Питрәч Сабантуен тагын да ямьләндереп җибәргән нәрсәләр булды. Беренчесе — «Питрәч» җырын язып, аны бөтен татар дөньясына тараткан «Бәйрәм» ансамбленең килүе...

Ә кичен, бәйрәм өстенә бәйрәм өстәп, игенче күптән зарыгып көткән яңгыр яуды.

Рәсемнәрдә сез Питрәч районының Күн авылында үткән Сабантуй мизгелләрен күрәсез.

Рәис НАСЫЙБУЛЛИН
Рамил ГАЛИЕВ (фото).





КАЗАН ТӨЗҮЧЕЛӘР КОЛЛЕДЖЫ

(КАЗАН ТӨЗҮЧЕЛӘР ТЕХНИКУМЫ БАЗАСЫНДА)
1991-92 НЧЕ УКУ ЕЛЫНА СТУДЕНТЛАР КАБУЛ ИТӘ.

Колледж ике дәрәҗәдәге белгечләр әзерли.

I дәрәҗә. «Биналар һәм корылмалар төзү» белгечлеге буенча 9—11 сыйныф тәмамлап кергән яшьләрдән производствоны оештыручы кече инженер-төзүчеләр, кече инженер-технологлар әзерли.

9 сыйныф тәмамлаучылар 4 ел да 6 ай, 11 сыйныф тәмамлаучылар 3 ел да 6 ай укыйлар.

«Төзелеш детальләре һәм тимер-бетон конструкцияләр җитештерү» белгечлегенә 9 сыйныф тәмамлаган яшьләр кабул ителә. Уку вакыты 4 ел да 6 ай. Студентлар бу белгечлекләргә көндез генә укыйлар.

II дәрәҗә. Көндезге уку бүлеге:

«Биналар һәм корылмалар төзү» белгечлегенә урта мәктәп тәмамлаган яшьләр кабул ителә. Уку вакыты 2 ел да 10 ай.

«Эретеп ябыштыру производствосы технологиясе» белгечлегенә 11 сыйныф тәмамлаганнар укый. Уку срогы 2 ел да 10 ай.

«Төзелештә бухгалтер учеты» белгечлегенә 11 сыйныф тәмамлаганнар кабул ителә. Уку вакыты 2 ел да 6 ай.

Читтән торып уку бүлеге:

«Биналар һәм корылмалар төзү» белгечлегенә урта белемле яшьләр кабул ителә. Уку вакыты 2 ел да 8 ай.

Төзелештә эшләгән бригадирлар һәм мастерлар уку вакыты ярты елга кыскартылган группаларга кабул ителәләр.

«Төзелештә бухгалтер учеты» белгечлегенә урта белемле яшьләр кабул ителә. Уку вакыты 2 ел да 6 ай.

Гаризалар 3 майдан 14 августка кадәр кабул ителә. Кабул итү кагыйдәләре башка техникумнардагы кебек үк.

Читтән торып уку бүлегенә укучылар предприятиеләр белән төзелгән килешүләр нигезендә кабул ителәләр. Абитуриентлар белән әңгәмәләр уздырыла.

Көндезге уку бүлегенә керүчеләр өчен имтиханнар 15 июльдә башлана. Көндез укучыларның барысына да стипендия түләнә, мохтаҗларга тулай торактан урын бирелә.

Колледжның адресы: 420075, Казан, Н. Липатов урамы, 25 нче йорт, телефоннар: 74-19-23, 74-13-21.

116 нчы профессиональ-техник училищеда укыячак яшьләр өчен торак мәйданы кирәк.

Укулар 1991 елның 1 сентябрендә башлана. Тәкъдимнәр белән шушы адрес буенча мөрәҗәгать итегез: Казан, Ершов урамы, 5 нче йорт («Акчарлак» ресторанын бинасы). Телефоннар: 76-64-03, 76-64-33, 76-64-53.

8 июнь көнне сәгать 10 да Буа районы Түбән Наратбаш авылы мәктәбе бинасында 1971 елда 8 классны тәмамлаган укучыларның

ОЧРАШУ КИЧӘСЕ

була. Рәхим итегез, классташлар!

116 нчы профессиональ-техник училище

9—11 СЫЙНЫФ ТӘМАМЛАГАН ЯШЬЛӘРНЕ, ПЕШЕКЧЕ, КОНДИТЕР, ПЕШЕКЧЕ-КОНДИТЕР, ОФИЦИАНТ ҺӨНӘРЛӘРЕН ҮЗЛӘШТЕРЕРГӘ ЧАКЫРА.

9 сыйныф тәмамлаганнар пешекче һәм пешекче-кондитер эшенә өйрәнү өчен 2 ел, ә урта мәктәп тәмамлаучылар пешекче, кондитер һәм официант булу өчен 8 ай ярым укыйлар.


Стипендия (компенсациядән тыш) 30 сум. Ә производство практикалары вакытында укучылар шуңа өстәп хезмәт хакының яртысын алалар. Чит шәһәрләрдән һәм авыллардан килеп укучылар практика вакытында тулай торакларда яшиләр. Училищеда укыган вакыт стажга керә.

Училищега кергәндә имтиханнар бирергә кирәкми.

Гаризалар һәр көнне (якшәмбедән кала) иртәнге 8 дән кичке 6 га кадәр, ә шимбәдә 9 дан 2 гә кадәр кабул ителә. Укулар 1 сентябрьдә башлана.

Училищеның адресы: Казан, Ершов урамы, 5 нче йорт («Акчарлак» ресторанны). 5 нче трамвай һәм 2, 7 нче троллейбуслар белән «Искра» тукталышына кадәр барырга. Телефоннар: 76-64-03, 76-64-33, 76-64-53.

Баш мөхәррир урынбасары Миңназыйм СӘФӘРОВ.



ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2, «Татарстан яшьләре».

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
Баш мөхәррир урынбасары — 53-07-52 (Миңназыйм Сәфәров).
Баш мөхәррир урынбасары — 53-07-50 (Рәис Насыйбуллин).
Җаваплы сәркатип — 53-07-50 (Айрат Салаватуллин).
Көн яңалыклары, вакыйгалар — 53-07-56 (Айрат Садыйк).
Хатлар — 53-07-58 (Рина Зарипова, Раилә Галиуллина).
Иҗтимагый тормыш — 53-07-56 (Флюра Низамова).
Сәяси тормыш һәм тәрҗемә — 53-07-54 (Роза Шәрәфиева).
Фән, мәгариф — 53-07-54 (Нәсимә Мөхәммәтсадыйк).
Табигать, авыл тормышы — 53-07-52 (Әлфия Самат).
Мәдәният-сәнгать — 53-07-54 (Мансур Мортазин).
Фотохәбәрче — 53-07-48 (Евгений Канаев).
Рәссам — 53-07-48 (Зоя Халилуллова).
Корректорлар — 53-07-48 (Илсөяр Гарипова, Альмира Зәйнуллина).
Машинисткалар — 53-52-34 (Гөлчәчәк Җәләева, Хәлидә Миңһаҗева).
Баш бухгалтер — 53-07-50 (Рәмзия Хәбибуллина).

«Татарстан яшьләре»нең учредителе — ВЛКСМның Татарстан республика комитеты. Газета атнага өч тапкыр — сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга. Индекс — 54121.

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

Тираж 250.000.

КПССның Татарстан республика комитеты нәшрияты типографиясендә басылды. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Заказ 5011.